**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

от 02.11.2020 года №02-07

**«Актаныш муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 21 июлендәге 16-04 номерлы Актаныш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль район Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 21 июлендә кабул ителгән 16-04 санлы карары белән расланган Актаныш муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (27.04.2018 ел, № 28-04, 16.09.2019 ел. №40-03, 09.11.2019 ел. №41-08, 26.02.2020 ел, №45-03, 12.08.2020 ел №47-05, 21.07.2020 №16-04, 11.09.2020 ел №48-03 үзг.белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 23 статьяның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Район Советының тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм район Советына карауга кертелгәннән соң кабул ителгән карар проекты агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына»;

1.2. 11 статьяның 14 пунктындагы 8 абзацында «6 абзацта» сүзен «6 һәм 8 абзацта», сүзләренә, «тиешенчә» сүзен «алынган» һәм «күрсәтелгән чараларны бирү максатларына ирешүгә бәйле» сүзләрен төшереп калдырырга «башка операцияләр» сүзләреннән соң , «очракларда» сүзләрен өстәргә, «муниципаль хокукый актлар белән» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, җирле администрация» сүзләрен өстәргә, «дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булып тормаган коммерциячел булмаган оешмаларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 56 статьяның 1 пунктында:

а) беренче абзацта «финанс органы» сүзләреннән соң «бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы» сүзләрен өстәргә;

б) 4, 6 һәм 7 пунктчалары үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.4. 10 статьяның 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. 41 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацында «яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әлеге орган исеменнән эш итәргә вәкаләтле башка зат» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе Э.Н.Фаттахов